

Балалар һәм vсмерләр арасында снюс яки «суыра торган тәмәке» коточкыч тизлектә тарала башлады. Аны хәзер балигъ булмаганнарга (несовешеннолетним) теләсә кайсы урыннарда, хәтта кибетләрдә дә саталар. Социаль челтәрләр дә шушы тотенсез тәмәкенен рекламасы белән тулган. Сәламәтлек саклау министрлыгы балалар һәм vсмерләрнен снюс куллануы бик куркыныч булуы турында кисәтә. Снюс буларак билгеле суыра торган тәмәкене куллану балаларда һәм vсмерләрдә никотинга бәйлелек тудыра, ул vз-vзенне агрессив булуга китерә һәм йокынын сыйфатын начарайта, дип белдерәләр Россиянен Сәламәтлек саклау министрлыгыннан белгечләр.      - Әлбәттә, сюслар бик куркыныч, - дип жавап бирә Республика наркология диспансеры баш табибы Анатолий Иванов. - Бу әфьюннын һәр пакетында балалар организмы очен шартлы рәвештә vлvче синтетик никотин дозасы - 40-90 мг.га кадәр. Кочсезлек, кvнел болгану, баш әйләнv, vз-vзенне тоту кагыйдәләрен бозу (психик бозулар булырга момкин) барлыкка килә; vлем белән тәмамлану куркынычы бар. Чиста никотин микъдарынын югары булуын исәпкә алып, сюсны берничә тапкыр кулланганда никотин бәйлелегенен тиз vсvе момкин. Шулай ук Ботендонья сәламәтлек саклау оешмасы экспертлары раславынча, аны кулланганда «авыз куышлыгы авырулары» килеп чыгу куркынычы бик югары. Тешләр какшау, пародонтоз, уртлар авырулары кvзәтелә.
Интернет чыганаклардагы табиблар белдерvенчә, снюста никотиннын концентрациясе бик югары, дип бил-гелиләр. Шуна да аны куллану бала сәламәтлеге очен куркыныч тудыра. Бары тик ноябрьдә генә мәктәп укучылары арасында снюс белән агуланунын берничә очрагы теркәлгән. Алтай краенда 8нче сыйныф укучысы тын ала алмый башлагач, реанимациягә эләгә. Соныннан ачыкланауынча, ул снюс кулланган була. Шуна охшаш хәл Яр Чаллы шәһәрендә дә булган. Кызганычка каршы, Новосибирск олкәсендә 7нче сыйныф укучысын коткара алмыйлар, ул никотиннан агуланып vлә. Снюс белән агулану очраклары Башкортстанда да булган. Унике яшьлек малайнын «кәнфит» ашап, дәваханәгә эләгvе турында матбугат басмалары язып чыкты. Унбиш яшьлек укучы мондый тотенсез тәмәкенен бер торен интернет аша заказ биреп алган була. Мәктәптә ул 12 яшьлек укучыны да сыйлый. Үсмер малайга әлеге снюсны кәнфит дип бирә.
Начар гадәт vсмерләр арасында тиз тарала, остәвенә, житештерvчеләр аларны кәнфит һәм мармелад рә-вешендә чыгара. Табиблар мәгъ-лvматларына караганда, Саранскида снюслар белән агуланганнан сон наркология диспансерына морәжәгатьләр булмаган. Мордовия Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгынын беренче урынбасары Елена Солдатова телеинтервьюсында: «Россия Федерациясендә тәмәке һәм башка никотинлы продукция куллануга каршы тору буенча дәvләт сәясәтен гамәлгә ашыру Концепциясе

нигезендә, республиканын барлык мәктәп укучылары арасында актив анлату эшләре алып барыла. Шулай ук медицина хезмәткәрләре катнашында ана-аналар жыелышлары vткәрелә. Куллану фактлары ачыкланган очракта, житәкчеләр Мәгариф министрлыгына һәм башка органнарга кичекмәстән хәбәр итәргә тиеш».
Сюсларнын зыяны турында хәбәрдар булмау һәм аларнын сәvдә челтәрендә булуы балалар һәм яшvсмерләрнен тиз таралуына һәм кулланылуына китерә.
- Тик топ куркыныч, - дип дәвам итә Анатолий Иванов, - бу тәмәке продукциясе житештерvче тарафыннан психоактив матдә буларак кулланылырга момкин яки наркотик матдәләрне маскировкаларга момкин. Ә бу наркотикларга бәйлелек vсvгә китерергә момкин. Россиядә, снюсларны сатуны тыю турында закон чаралары 2015нче елда кабул ителvгә карамастан, житештерvчеләр бу куркыныч матдәләрне сату очен закондагы лазейкаларын таба. Сюслар сатуны катгый контрольдә тоту чаралары кирәк. Сvз унаенда, кайбер тобәкләрдә кибет киштәләрендә агулы пакетлы «шайбалар»ны гына тvгел, ә бәлки охшаш составнын мармеладын һәм хәтта никотин белән теш чистарту таякчыкларын да саталар. Бу хәл тиз арада жавап бирvне һәм законнарны катгыйландыруны таләп итә. Федераль массакvләм мәгълvмат чаралары хәбәр иткәнчә, Дәvләт Думасы депутатлары тиешле инициатива белән чыккан инде. Тиздән норматив актлардагы житешсезлекләр бетерелер дип ометләнәбез.

**Н.Хәлил**